**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Түбән Биш авыл җирлегенең Түбән Биш торак пунктында**
**2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**
**гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

2023 елның 22 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Түбән Биш авыл җирлеге Түбән Биш торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Түбән Биш авыл җирлеге Түбән Биш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, шул исәптән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә
- мөселман зиратын төзекләндерү (койма белән әйләндереп алу);
- Дзержинский урамындагы юлларга өлешчә вак таш салу;
- урам утларын ремонтлау.
3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә (Түбән Биш авыл җирлеге Уставының 69 п.5 статьясы) Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «авыл җирлекләре» бүлегендә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Биш авыл җирлеге башлыгы Д.В.Насертдинов